**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.06.2024 г.Казань №318

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 1 июленнән «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында» 821 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

**б о е р а м :**

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 12 сентябрендә кул куелган 439 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 2008 елның 25 декабреннән «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы федераль закон, коррупциягә каршы көрәш максатларында башка федераль законнар белән Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы чикләүләр һәм тыюларны, таләпләрне (алга таба – хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) үтәүне тәэмин итүдә;»;

15 пунктны түбәндәге эчтәлекле «е» подпункты белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында хәбәр итүе.»;

16.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» подпунктының бишенче абзацында һәм «е» подпунктында күрсәтелгән хәбәрләр Министрлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан кадрлар мәсьәләләре һәм дәүләт хезмәте секторында карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмәләр әзерли.»;

16.4 пунктында «15 пунктның «д» подпунктында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» подпунктларында» сүзләре белән алмаштырырга;

16.5 пунктында:

«а» подпунктында «15 пунктның «д» подпунктында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» подпунктларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, 24.2, 24.3, 25.2 пунктлары яисә башка карар нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен дәлилле тәкъдимнәр.»;

17.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән хәбәрләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

18 пунктта «15 пунктның «б» подпунктында» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» подпунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

18.1 пункттагы «а» подпунктында «15 пункттагы «б» подпунктында» сүзләрен «15 пункттагы «б» һәм «е» подпунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 24.3 пункт өстәргә:

«24.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «е» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәл-сәбәпләр һәм аның тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмау арасында бәйләнеш булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмаву һәм аңа бәйле булмаган хәл-сәбәпләр арасында бәйләнеш булмавын танырга.»;

26 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» подпунктларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм шуңа нигезләмәләр булган очракта комиссия әлеге Нигезләмәнең 21 – 24.3 һәм 25.1 – 25.2 пунктларында каралганнан тыш башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

Министр В.А. Леонов